**Казан шәһәре Думасының**
**2025 елның 12 августындагы 18-40 номерлы карары**

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә иҗтимагый-җитештерү объектларын урнаштыруның территориаль зонасы (ОП) (106 номерлы контур) чикләрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 20 статьясы нигезендә, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 3 июлендәге 2044 номерлы «Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә иҗтимагый-җитештерү объектларын урнаштыру территориаль зонасы (ОП) (106 номерлы контур) чикләрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү кертү турында Казан шәһәре Думасы карары проектын әзерләү хакында»гы карарын һәм 2025 елның 10 июленнән 2025 елның 24 июленә кадәр үткәрелгән иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Казан шәһәре Думасы **карар бирде:**

1. Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (алга таба – Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасында, әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендә территориаль зона – катнаш торак һәм иҗтимагый төзелеш зонасын (ОЖ) (78 номерлы контур) 16:50:000000:38608, 16:50:080408:4 кадастр номерлы җир кишәрлекләренә карата билгеләп, территориаль зона – иҗтимагый-җитештерү объектларын урнаштыру (ОП) (106 номерлы контур) зонасы чикләрен үзгәртергә;

1.2. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән территориаль зоналарның үзгәрә торган чикләрен Кагыйдәләр составында шәһәр төзелешен зоналаштыруның түбәндәге карталарында чагылдырырга:

- шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы;

- территориаль зоналарның урам-юл челтәре, табигать-рекреация комплексы, махсус билгеләнештәге яшелләндерү, яр буе территорияләре ярдәмче зоналары күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

- территориаль зоналарның территориядән югары интенсивлыкта файдалану, шәһәр төзелешендә әһәмияткә ия территорияләр ярдәмче зоналары күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

- территориаль зоналарның ярдәмче зоналары: тарихи җирлек ярдәмче зонасы күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

- чикләрендә территорияләрне комплекслы үстерү күздә тотыла торган территорияләр картасы;

1.3. Кагыйдәләргә 1 номерлы кушымтаны әлеге карарга 2 номерлы кушымта (хезмәт урынында файдалану өчен) (китерелми) нигезендә территориаль зоналар чикләре урнашу урынының график тасвирламасы белән тулыландырырга;


1.4. Кагыйдәләрнең 2 номерлы кушымтасына әлеге карарның 3 номерлы кушымтасы нигезендә территориаль зоналар чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеген (хезмәт урынында файдалану өчен) (китерелми) өстәргә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәре Думасының
2025 елның 12 августындагы
18-40 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы фрагменты**




**Шартлы билгеләр**

**ОЖ - 78**

Территориаль зона контурының тәртип номеры

Территориаль зона индексы

**Территориаль зоналар**

| **Төс** | **Индекс** | **Территориаль зона төренең атамасы** |
|---|---|---|
| | ОП | Иҗтимагый-җитештерү объектларын урнаштыру зонасы |
| | ОЖ | Катнаш торак һәм иҗтимагый төзелеш зонасы |
| | | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы фрагменты чиге |

**Башлык урынбасары** **Е.А.Лодвигова**